**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 44-10 «___» ______ 2021ел

«Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2016 елның 25 октябрендәге 34-9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (13.07.2017 №52-17, 24.01.2018 №82-22, 12.11.2018 №113-28, 23.05.2019 №139-33, 26.11.2019 №152-37)

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге уставының 32 статьясы нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы
карар итте:

1. «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2016 елның 25 октябрендәге 34-9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (13.07.2017 №52-17, 24.01.2018 №82-22, 12.11.2018 №113-28, 23.05.2019 №139-33, 26.11.2019 №152-37)

1.1. 4 пунктында:

- тугызынчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) парклар администрацияләре, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында аккредитация узган җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә төзелгән, шулай ук муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) паркларына тапшырылган һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында аккредитация үткән җирләр милекчеләре, индустриаль (сәнәгать) парклар администрациясенә аффилирланган затлар тарафыннан карый торган җир кишәрлекләрен арендалаучылар;».

2. Әлеге карар рәсми басма - «Маяк» газетасында басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә һәм 2011 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны район «Маяк» газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru-Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырылган: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин